Гомуми усеш бирүче 4 нче санлы балалар бакчасы

[Введите название организации]

# Балаларнын сәламәт үсүендә хәрәкәтле уеннарның әһәмияте.

Гомуми ата – аналар җыелышы өчен чыгыш

Физкультура инструкторы:
Сарварова Альбина Эрнистовна

Декабрь. 2017 ел.

# *Балаларнын сәламәт үсүендә хәрәкәтле уеннарның әһәмияте.*

Уен – ул балалар тормышнда иң әһәмиятле чара.  Уеннар тирә- юньне, дөньядагы күренеш һәм предметларны аңлауда, аларны дөрес кабул итүдә иң төп чараларның берсе булып тора. Бала иң беренче эш күнекмәләрен дә нәкъ менә уеннар аша ала. Уен аша балалар  дөньяны танып беләләр.. Уеннар, элек-электән күңел ачу чарасы гына булып калмыйча, иң беренче чиратта тирә-юньне, дөньяны танып белүдә, тормышта иң кирәкле булган белем һәм күнекмәләрне үзләштерүдә дә зур роль уйнаганнар. Шуңа күрә дә без тәрбиячеләр балалалар бакчасында барлык тәрбия чараларын да уен аша бирергә тырышабыз. Уеннар була күп төрле: сюжетлы – рольле уеннар, дидактик уеннар,  хәрәкәтле уеннар. Без бүген хәрәкәтле уеннарга тукталып китәрбез. Физкультура шөгылендә без иң элек гимнастик күнегүләр ясыйбыз. Аннан соң төп хәрәкәтләрне өйрәнәбез. Һәм хәрәкәтле уенга күчәбез.  Хәрәкәтле уеннар йөгерүле, сикерүле, ыргытулы һ. б. шундый төрләргә бүленәләр. Йөгерүле уеннарның максаты – балаларда туры һәм төрле юнәлештә йөрү, йөгерү күнекмәләре булдыру, сигнал буенча хәрәкәт башкара белүләрен үстерү, бер-бер артлы тезелеп йөрергә һәм йөгерергә, бер-берсен куып тотарга өйрәтү, игътибарлылык, җитезлек, өлгерлек тәрбияләү. Сикерүле уеннар ярдәмендә балалар бер урында, ике аякта берьюлы, югарыдан түбәнгә, озынлыкка сикерергә өйрәнәләр;. Ыргытулы уеннар ярдәмендә балалар туп тәгәрәтеп уйнарга, бер-берсенә туп тапшырырга, гәүдәне уңга һәм сулга борырга, хәрәкәт итүче бер ноктага атып тидерергә өйрәнәләр.   Шөгыльнең ахырында аз хәрәкәтле  яки җырлы-биюле уен белән балаларны тынычландырып шөгыльне тәмамлыйбыз. Аз хәрәкәтле уеннар балаларның игътибарлылыгын, күзәтүчәнлеген, хәтерен, дикъкатен арттыруга, тапкырлыкларын үстерүгә, зиһеннәрен ныгытуга ярдәм итә. Әлеге уеннар ярдәмендә балаларда сабырлык, түземлелек, кыюлык, гаделлек кебек әхлакый сыйфатлар да тәрбияләнә.

Уен ул – сәламәтлек чыганагы. Тән сәламәтлеге белән бергә, баланың рухи яктан дөрес формалашуы иң беренче чиратта уеннар һәм аларның дөрес оештырылуына бәйле. Шуңа күрә балалар бакчаларында да, гаиләдә дә уеннарны дорес итеп оештыруга җитди игътибар итәргә кирәк. Уеннар никадәр кызыклырак итеп оештырылса, аларның файдасы шулкадәр зуррак. Балаларга алар яратмаган уенны көчләп тагарга ярамый. Өлкәннәр барлык төр уеннарны да җанлы, кызыклы, тәэсирле итеп оештыра белергә тиешләр. Иң мөһиме – балаларны уенга җыя, туплый белү. Моның өчен балаларда уенга карата кызыксыну уятырга кирәк. Рәсемнәр, төрле уенчыклар күрсәтү, я булмаса алдан

уенның эчтәлеген ача торган шигырь яки әкият сөйләү моңа зур булышлык итә. Мәсәлән, без буген “Аю урманында “ дигән уен уйнадык. Мин балаларга аю турында табышмак әйттем: “җәен урманга хуҗа, кышын кардан да аста”. Табышмакның җавабын алгач, “Әйдәгез бергәләшеп аю янына урманга барып кайтабыз” дип уенны башлап җибәрдек. Уен бик күңелле һәм җанлы узды.

Физкультура шөгыльләрендә һәм хәрәкәтле уеннар вакытында баланың сулыш, кан йөреше, нерв системасының тонусы нормальләшә, ашказанындагы һәм организмдагы матдәләр алмашы яхшыра. Уеннар шулай ук баланың физик һәм уйлау-фикерләү сәләтен үстерә. Мәсәлән , “Фигура ясa “уенында бала уйлап , сигнал булуга нинди дэ булса бер позада калырга тиеш (әкият, мультфильм геройлары булып калалар, бер-берсен кабатламаса тырышалар) ,. Ә “игътибарлы бул” уенында бала мин әйткән санга дөрес хәрәкәт ясарга тиеш. Бу аларның хәтерләрен яхшырта, игътибарлылыкларын арттыра

Уеннар, бер яктан, физик тәрбия чарасы булса, икенче яктан күп кенә уеннар эстетик тәрбия бирүгә зур ярдәм итә. Хәрәкәтләрнең төгәллеге, уенның сүзләрен сәнгатле итеп әйтү, балаларның төрле образлар башкарулары- болар барысы да балаларда канәгатьләнү хисләре уята, матурлыкны аңларга ярдәм итә. Алай гына да түгел, уен вакытында баланың күңеле күтәренке, көр була, бу халәт аның нерв системасына уңай йогынты ясый. Уен вакытында туган шатлыклы кичерешләр уенны көчле тәрбия чарасына әверелдерә.. Уен ярдәмендә оялчан, үз эченә бикләнгән балаларны да уятырга мөмкин. Уендагы текстка, җырга кушылып, аның кагыйдәләрен үтәп, йә булмаса ниндидер роль башкарып бала үз көченә ышанырга, эшләгән эшенә бәя бирергә өйрәнә, анда башкаларның хәленә керә белү, ярдәмләшү, игътибарлылык кебек сыйфатлар тәрбияләнә.

Уенның кагыйдәләрне үтәү дә зур тәрбияви әһәмияткә ия. Уен кагыйдәләренә буйсыну балаларда түземлелек, тәртиплелек, ихтыяр көче, тотнаклылык тәрбияли. Уеннарның дәвамлылыгы балаларның йөрәк эшчәнлегенә артык көч китерерлек, аларны ардырырлык булырга тиеш түгел. Хәрәкәтле уеннарның уртача дәвамлылыгы кечкенәләр төркемендә 5-6 минут, урта яшьтәге балалар төркемендә 6-8 минут, ә өлкәнрәк төркемнәрдә 8-10 минут.

3-4 яшьлек балалар белән җитезлек, өлгерлек, сабырлык таләп итә торган уеннар уйнарга кирәк. Уеннарга тизлеккә йөгерү, сикерү, төз ыргыту кебек хәрәкәтләр кертелә. Бу яшьтә сүзле уеннар киң кулланыла. “ Аю урманында”, “йонлач көчек” уеннары шундыйлардан. Әлеге уеннар балаларның сөйләм телләрен үстерүгә дә булышлык итә.

5-6 яшьтә балалар алдагы елларга караганда да игътибарлырак, күзәтүчәнерәк, кызыксынучанырак булалар. Уеннарның эчтәлеге байей. Әлеге яшьтә балалар җырлы-биюле, зиһен сынаш һәм хәрәкәтле уеннарны бик теләп уйныйлар. Уеннар йөгерү, сикерү, ыргыту, үрмәләү кебек төп хәрәкәтләргә нигезләнеп төзелә. Балалар уенның нәтиҗәсе белән күберәк кызыксыналар, шунлыктан уеннарга ярыш элементлары кертелә. Балалар башкалар белән эш-гамәлләрен килешеп башкарырга, иптәшләренең фикерләренә колак салырга, максатларына ирешү юлларындагы каршылыкларны җиңә белергә өйрәнәләр.

6-7 яшьлек балалар туплар, сикергечләр, кыршаулар белән яратып уйныйлар. Ярышлы уеннарга игътибарлары арта: алар бик теләп командаларга, звеноларга бүленәләр. Төрле физик күнегүләр, спорт һәм халык уеннары балаларның хәрәкәт эшчәнлегенә булган ихтыяҗын канәгатьләндерүдә әһәмиятле чара булып тора. Балалар белән сигнал буенча хәрәкәт башкара белү, пространствода үз урыннарын таба белергә, өлгерлек, җитезлек, игътибарлылык кебек ихтыяри сыйфатлар тәрбияләүгә булышлык итүче уеннар уйнала.

Хөрмәтле Эти - энилэр! Балалар белән өйдә дә уеннар уйнарга вакыт табарга , алар белән күбрәк аралашырга кирәклеген без барыбыз да аңлыйбыз. Балалар бакчасында уйнаган уеннар балаларга бик файдалы булса, ә гаиләдә, табигать кочагында уйнаган уеннар икеләтә кызыклырак һәм мин әйтер идем нәтиҗәлелерәк. .

“Бала аң эшчәнлегенә һәм тирән фикерләү сәләтенә ия булсын өчен, аның сәламәтлеге турында кайгыртырга кирәк: ул йөгерсен, сикерсен, көч түксен-һәрвакыт хәрәкәттә булсын”

Ж.Ж.Руссо.